ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 август, 2017 ел № 18/9

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10 санлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 31 нче маддәнең

- 9 өлеше 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхси яки ышанычлы вәкилләр аша эшмәкәрлек белән шөгыльләнү, коммерцияле яйсә коммерцияле булмаган оешмаларның идарә итү органнарында катнашу (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партияләрдә, башка иҗтимагый оешмаларның

съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында, торак, торак төзелеше, гараж кооперативлары, бакча, дача кулланучылар кооперативлары, берлекләре, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан башка), федераль законнар белән каралган башка очраклардан тыш һәм оешма белән идарә итү Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән башкарылса;»;

- 9.2 – 9.4 өлешләрен түбәндәгечә тулыландырырга

«9.2 Депутатның, җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасының, жирле үзидарәнең сайланып куелган вазифаи затының Россия Федерациясенең коррупциягә каршы торуга юнәлтелгән законнары нигезендә тапшыра торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти йөкләмәләр турында мәгълүматларының дөрес һәм тулы булуын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты карары белән Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

9.3 Әлеге маддәнең 9,2 өлешендә каралган тәртиптә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тотуны, акчалата чаралар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турындагы» 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү фактлары ачыкланганда Татарстан Республикасы Президенты Шәһәр Советына яйсә судка депутатның, җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифаи затының вәкаләтләрен вакытыннан алда төгәлләү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

9.4 Муниципаль вазифаны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти йөкләмәләр турында мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында һәм (яйсә) муниципаль хокукый актлар нигезендә каралган тәртиптә массакүләм матбугат чараларында урнаштырыла.»

- 11.1 өлешен түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«11.1 Депутатларның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук, очрашу үткәрү халык яшәешен тәэмин итү объектлары, транспорт һәм социаль инфраструктура, элемтә эшчәнлегенә зыян китермәгән жәяүлеләр һәм (яйсә) транспорт хәрәкәтенә комачаулык тудырмаган, гражданнннарнын торак биналарга, транспорт һәм социаль инфраструктура объектларына керү мөмкинлеген чикләмәген очракта, ишек алды территорияләрендә

уздырылаю Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына яки Башкарма комитетка мондый очрашулар үткәрү хакында хәбәрнамә җибәрү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга очрашу үткәрү көне һәм вакыты хакында хәбәр итәргә хокуклы.

Башкарма комитет депутатларның сайлаучылар белән очрашуын уздыру өчен махсус урыннар билгели, депутатларның сайлаучылар белән очрашуын үткәрү тәгаенләнгән биналарның исемлеген һәм аларны бирү тәртибен раслый.

Депутатның сайлаучылар белән очрашуы гавами чара формасында һәм Россия Федерациясенең җыеннар, митинглар, демонстрацияләр, халык йөрешләре һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә башкарыла

2) 32 маддәнең 3 өлешен түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Президентыннан Шәһәр Советы депутатын вакытыннан алда вәкаләтләреннән азат итү турында гариза кергән очракта, вакытыннан алда вәкаләтләрдән азат итү нигезе булып Шәһәр Советына гариза кергән көн санала.»;

3) 35 маддәнең 1.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«1.1 Шәһәр Хакиме 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тотуны, акчалата чаралар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турындагы» 79-ФЗ санлы Федераль законы нигезендә вазифаларын башкарырга, чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.»

4) 40 маддәнең

- 4.3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3 Башкарма комитет Җитәкчесе 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тотуны, акчалата чаралар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турындагы» 79-ФЗ санлы Федераль законы нигезендә вазифаларын башкарырга, чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.»

- 5 өлешнең 3 пунктында «6 өлеше» сүзеннән соң «яки 6.1» дип өстәргә;

- 6.1 өлешен түбәндәге эчтәлектә өстәргә:

«6.1 Башкарма комитет Җитәкчесе белән контракт Татарстан Республикасы Президенты гаризасы нигезендә суд тәртибендә Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору хакындагы законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү барышында 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тотуны, акчалата чаралар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турындагы» 79-ФЗ санлы Федераль законы нигезендә чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү очраклары ачыкланганда өзелә.».

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевкә әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юнәлтергә.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2017 елның 29 августында теркәлгән. Дәүләти теркәү номеры № RU 163020002017002.